**СОВЕТ КРАСНООКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423193, РТ, Новошешминский район, поселок совхоза «Красный Октябрь», улица Школьная, 3

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ОКТЯБРЬ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
423193, РТ Яңа Чишмә районы ,Кызыл Октябрь с-зы поселогы , Мәктәп урамы, 3

тел.:(884348)33-2-28, факс: (8-84348)33-2-09, Kokt.Nsm@tatar.ru

КАРАР КАРАР

2020 елның «30» октябреннән № 4

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Гарь поселогы гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «Красный Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22, 81 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь җирлеге башлыгы

Карар кабул итте:

1. 2020 елның 21 ноябренә сәгать 10. 00 да Нагорная урамындагы 10 йорт янында Красный Октябрь авыл җирлегенең Гарь поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын үткәрү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлеге Башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Гарь поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, БВСда катнашучылар, БВСда һәм һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучының тол хатыннары, балачактан инвалидлар, 1 төркем инвалидлардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә алынган акчаларны Гарь поселогы территориясендә түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:

- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- җәйге чорда территориядәне чүп үләннәреннән чистарту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны гражданнар җыены уздырыла торган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа

Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә), Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Красный Октябрь авыл җирлегенең Гарь авылының мәгълүмат стендында урнаштырырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Красный Октябрь авыл җирлеге Башлыгы В.В. Захаров